ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№370 от «02» 11 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 4 февралендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирүче бер оешмадан укучыларны тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешмаларга күчерү Тәртибен һәм шартларын раслау турында» 44 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты, 2022 елның 24 сентябрендәге 371-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 4 февралендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирүче бер оешмадан укучыларны тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешмаларга күчерү Тәртибен һәм шартларын раслау турында» 44 номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрнге кертергә:

1.1 Әлеге Карарга 1 нче кушымтаның 5.12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру, белем алучыларның белем

0000011428

белем бирү ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алып, тиешле белем бирү программасының аерым уку предметларын, предметлы өлкәләрен тирәнтен өйрәнүне (профильле укыту) күздә тота ала.»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» һәм Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru// рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.Р. Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов